Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Түбән Кондрата авыл җирлеге Советы

Карары

2026 елның «16» феврале №7/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Түбән Кондрата авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Түбән Кондрата авыл җирлеге «муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында» 10.02.2023 елның №31/1 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 28.11.2025 ел, № 432-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Түбән Кондрата авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Түбән Кондрата авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында «10.02.2023 ел, №31/1 авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Түбән Кондрата авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.1 маддәнең 7 пунктында «(муниципаль берәмлек)» сүзләреннән соң «, әгәр күрсәтелгән акчалар федераль казначылык органнары тарафыннан ачыкланмаган керемнәргә керсә һәм тиешле казначылык счетларында исәпкә алынса, бу очрактан тыш», сүзләрен өстәргә.;

1.2. 5.1 маддәнең 13 пунктында «федераль законнар» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясе субъекты законнары, җирле үзидарә вәкиллекле органының муниципаль хокукый актлары» сүзләрен өстәргә.;

1.3. 5.1 маддәнең 11 пунктындагы 1 пунктчасының бишенче абзацында «контрактлар (шартнамәләр)» сүзләреннән соң «товарлар кайтару, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында» сүзләрен өстәргә.;

1.4. 5.1 маддәнең 11 пунктының 4 пунктчасында «коммерциягә карамаган оешмаларга» сүзләреннән соң «(шартларында казначылык озатуы турындагы нигезләмәләр булган дәүләт контрактлары, шартнамәләр (килешүләр), контрактлар (шартнамәләр) нигезендә бирелә торган акчалардан тыш)» сүзләрен өстәргә.;

1.5. 5 маддәнең 12 пунктындагы 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 221 маддәсе нигезендә билгеләнә торган тәртиптә бюджет сметасын төзи, раслый һәм алып бара;».

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга) һәм Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтына (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Авыл җирлеге башлыгы О. Д. Родионова